**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**IV чакырылыш XV утырыш**
КАРАРЫ

2023 елның 31 октябре №48 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә, аларга карата генераль план әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 №18 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2023 елның 19 октябрендәге 10-53/12943 номерлы бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Ютазы муниципаль районын территориаль планлаштыру схемалары турында» 2012 елның 21 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Аксакүл поселогы, Байлар авылы;
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Ташкичү авылы, Хөррият авылы;
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Бәйрәкә авылы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы рәисе А.Ә. Шәфигуллин